**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня, улица
Ш.Марджани,
дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы,
6нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» гыйнвар 2025 ел. № 31

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» 30.07.2010 елгы 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Әтнә район башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. Әтнә районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген яңа редакциядә раслау хакында» 26.06.2019 ел, 184 номерлы карарын;

2.2. Әтнә район башкарма комитетының «РИК ның 20.12.2022 ел, №496 карарына үзгәрешләр кертү турында» 14.09.2023 ел, 671 номерлы карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (http://atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Житәкчесе А.Ф. Каюмов

Кушымта
Татарстан Республикасы
Әтнә районы башкарма комитеты
31. 01. 2025 ел
№ 31 карарына

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

| *ТР КоАП маддәләре* | *Вазыйфаи затлар исемлеге* |
|---|---|
| **2.1 маддә ТР КоАП.** Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (элмә тактада Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешма үз исеме турында белешмәләрне һәм элмә тактада урнаштырылырга тиешле башка мәгълүматны күрсәткәндә телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозуларга карата)<br>**2.4 маддә ТР КоАП.** Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр<br>**2.5 маддә ТР КоАП.** Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яисә йөртү<br>**2.7 маддә ТР КоАП.** Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу<br>**2.12 маддә ТР КоАП.** Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу<br>**2.13 маддә ТР КоАП.** Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак гражданнарны исәпкә алу һәм исәпкә алу тәртибен бозу<br>**2.15 маддә ТР КоАП 2 нче өлеше.** Терроризмны профилактикалау, аның чагылышлары нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яисә) бетерү буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яисә бозу<br>**2.21 маддә. ТР КоАП.** Режим (база әзерлеге дәрәҗәсе) кысаларында чараларны гамәлгә ашыруны күздә тота торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү<br>**3.3 маддә. ТР КоАП.** Җир асты коммуникацияләрен тоту кагыйдәләрен бозу<br>**3.4 маддә. ТР КоАП.** Урамнарны, квартал эчендәге яктыртуны тоту кагыйдәләрен бозу<br>**3.6 маддә. ТР КоАП.** Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу<br>**3.10 маддә. ТР КоАП.** Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен бозу<br>**3.16 маддә. ТР КоАП.** Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибен бозу<br>**3.17 маддә. ТР КоАП.** Транспорт чараларын | Әтнә районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы; Әтнә районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече |

| | |
|---|---|
| яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннар йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру<br>**4.4 маддә. ТР КоАП.** Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм күрсәтелгән объекттан файдалану тәртибен бозу<br>**5.1 маддә. ТР КоАП.** Пассажирның юл йөрү өчен түләүне, үзе белән бергә йөрүче балаларны йөртүне раслау, шулай ук пассажирның түләүсез яисә ташламалы юл йөрү хокукын раслау тәртибен бозу<br>**5.2 маддә. ТР КоАП.** Пассажирның багаж ташу, кул йөге ташу өчен түләүне раслау тәртибен бозу<br>**5.6 маддә. ТР КоАП.** Пассажирга юл бирүдән баш тарту | |
| **2.6 маддә. ТР КоАП.** Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү<br>**2.19 маддә. ТР КоАП.** Балигъ булмаганнарга алкогольсез тонизиручы эчемлекләрне ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук балигъ булмаганнарны аларны куллануга җәлеп итү<br>**2.20 маддә. ТР КоАП.** Сыекландырылган углеводород газы булган гражданнарның шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен товарларны балигъ булмаганнарга ваклап сатуны чикләүне үтәмәү, шулай ук сыекландырылган углеводород газын сулау юлы белән балигъ булмаганнарны куллануга җәлеп итү<br>**3.2 маддә. ТР КоАП.** Урамда сәүдә итүне оештыру һәм халыкның күңел ачуына бәйле хезмәтләр күрсәтү тәртибен бозу<br>**3.5 маддә. ТР КоАП** Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу<br>**3.8 маддә. ТР КоАП** Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу | Әтнә район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;<br>Әтнә район башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге начальнигы; |
| **2.17 маддә. ТР КоАП** Яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19)таралуны булдырмауга һәм нәтиҗәләрен бетерүгә юнәлдерелгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары таләпләрен үтәмәү<br>**3.11 маддә. ТР КоАП** Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүгә карата таләпләрне үтәмәү<br>**3.15 маддә. ТР КоАП** Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү<br>**3.15.1 маддә. ТР КоАП** Җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәтләрне көчләп тагу | Татарстан Республикасы Әтнә район Башкарма комитетының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау секторының әйдәп баручы белгече (балигъ булмаганнар арасында гаилә иминсезлеген һәм хокук бозуларны профилактикалау буенча) |
| **3.14 маддә. ТР КоАП** Мәдәни-тамаша чараларына барганда җәмәгать тәртибен бозу | Әтнә район башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе |